ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 112-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Р. Баксиков һәм А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 112-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 403-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.Р. Баксиков, А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын яисә атасын йә анасын югалткан затлар (төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары, төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча уку чорында ата-анасы яисә атасы йә анасы вафат булган 18 яшьтән алып 23 яшькә кадәрге затлар), шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар әлеге затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсә;»;

2) 2 өлешнең $10^2$ пунктында «затларның» сүзеннән соң «һәм уку чорында ата-анасын яисә атасын йә анасын югалткан затларның» сүзләрен өстәргә;

3) 3 өлешнең 2 пунктында:
а) «г» пунктчасында «затларга» сүзеннән соң «, уку чорында ата-анасын яисә атасын йә анасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;
б) «д» пунктчасында «затларның» сүзеннән соң «, уку чорында ата-анасын яисә атасын йә анасын югалткан затларның» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 10 статьясына һәм «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 июлендәге 340-ФЗ номерлы Федераль закон белән түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган затларның категорияләре конкретлаштырылды: әлеге хокук уку чорында ата-анасын яисә атасын йә анасын югалткан 18 яшьтән алып 23 яшькә кадәрге затларга, шулай ук әлеге затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткәндә аларның вәкилләренә бирелде.

Югарыда әйтелгән үзгәрешләр «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына торган нигезләмәләргә кагыла, шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән республика законына тиешле үзгәрешләр кертелә.

Закон проекты ике статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясында 12 статьяга үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

2 статьяда Татарстан Республикасы законының үз көченә керү тәртибе билгеләнә: ул рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башка Татарстан Республикасы законнарын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга хезмәт хакы түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 21 октябрендәге 774 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.